| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 6 апрель № 224

г. Казань

«Бөгелмә һөнәр-педагогика көллияте» дәүләт бюджет һөнәр белеме бирү учреждениесен һәм «Бөгелмә педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәр белеме бирү учреждениесен үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасының һөнәр белеме бирү оешмалары челтәрен оптимальләштерү, квалификацияле эшчеләр һәм урта звено белгечләрен әзерләүнең сыйфатын күтәрү, кадрлар әзерләү күләмнәрен арттыру һәм хезмәт ресурсларыннан тагын да нәтиҗәлерәк файдалану максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Бөгелмә һөнәр-педагогика көллияте» дәүләт бюджет һөнәр белеме бирү учреждениесен (алга таба – Бөгелмә һөнәр-педагогика көллияте) һәм «Бөгелмә педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәр белеме бирү учреждениесен (алга таба – Бөгелмә педагогика көллияте), Бөгелмә һөнәр-педагогика көллияте эшчәнлегенең төп максатларын саклап, Бөгелмә педагогика көллиятен Бөгелмә һөнәр-педагогика көллиятенә кушу рәвешендә үзгәртеп оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Бөгелмә һөнәр-педагогика көллиятен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкарырга;

бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән оешмаларны үзгәртеп оештыруга бәйле булган законнарда каралган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

Бөгелмә педагогика көллиятендә белем алучыларны Бөгелмә һөнәр-педагогика көллиятенә күчерүне, аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән, белем бирү шартларын һәм программаларын саклап, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон һәм «Мәгариф турында» 2013 ел, 22 июль, ТРЗ-68 нче Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәп тәэмин итәргә;

үзгәртеп оештыру чаралары аркасында эштән азат ителүче хезмәткәрләргә законнар нигезендә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

30 көн эчендә түбәндәгеләргә тиешле үзгәрешләр кертергә:

Бөгелмә һөнәр-педагогика көллияте уставына;

Бөгелмә һөнәр-педагогика көллияте өчен гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсенә.

4. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Бөгелмә һөнәр-педагогика көллияте уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган көннән 30 көн эчендә элек оператив идарә хокукында Бөгелмә педагогика көллиятенә беркетелгән дәүләт мөлкәтен Бөгелмә муниципаль районына тапшырырга.

5. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертергә.

6. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карарына аны бу карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\224.doc